КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 23 март г.Казань № 157

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисадый саммитын үткәрү турында» 2016 ел, 5 февраль, 71 нче карары белән расланган «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисадый саммитын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисадый саммитын үткәрү турында» 2016 ел, 5 февраль, 71 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 8 сентябрь, 646 нчы; 2019 ел, 5 март, 152 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисадый саммитын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

оештыру комитеты составыннан М.Г.Әхмәтовны, Р.Р.Гыйматдиновны, А.Р.Зариповны, А.В.Мәүликовны, Л.Р.Сафинны, А.А.Старостинны, Р.А.Шәйхетдиновны чыгарырга;

оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Газинур Тәлгать улы Бакировны (килешү буенча);

Татарстан таможнясы башлыгы Марат Мәсгут улы Гәрәевны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Азат улы Җәббаровны;

«Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Сергей Анатольевич Романцовны (килешү буенча);

Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәетгәрәй улы Сәлимгәрәевны;

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Ринат улы Хәйруллинны;

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Мөдәррис улы Хәнифовны;

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры Мидхәт Рәфкать улы Шаһиәхмәтовны;

Фәрит Солтан улы Габделганиевның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин